КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 27 декабрь г.Казань № 1219

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елда «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының («Алабуга-2» индустриаль паркы) әлеге юридик зат милкендә булган капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыру өчен, алга таба Россия Федерациясе законнары нигезендә «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенең устав капиталын арттырып, Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында» 2023 ел, 7 декабрь, 1571 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елда «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының («Алабуга-2» индустриаль паркы) әлеге юридик зат милкендә булган капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыру өчен, алга таба Россия Федерациясе законнары нигезендә «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенең устав капиталын арттырып, Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында» 2023 ел, 7 декабрь, 1571 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 28 декабрь, 1713 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2023 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «(алга таба – субсидия)» сүзләрен «(алга таба – 2023 елда субсидия)» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 1[1] пункт өстәргә:

«1[1]. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2024 елда 100 процент акцияләре (өлешләре) Татарстан Республикасыныкы булган акционерлык җәмгыятенә «Эт-600» индустриаль паркының акционерлык җәмгыяте милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 1 660 000 000,0 сум күләмендә субсидия (алга таба – 2024 елда субсидия) бирү юлы белән 1 нче һәм 3 нче кушымталар нигезендә ярдәм чаралары күрсәтү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.»;

2 пунктның өченче абзацында «субсидия» сүзе алдына «2023 елда» сүзләрен өстәргә;

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

2024 елда субсидия «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) парклар булдыру һәм үстерү» төбәк проектын гамәлгә ашыру өчен бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.»;

әлеге карарның 1 һәм 2 нче кушымталарын яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә;

әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 7 декабрь, 1571 нче карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 27 декабрь, 1219 нчы карары редакциясендә)

## «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте милкендә булган, капитал салулар гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектлары

| Т/с | Капиталь төзелеш объекты-ның исеме | Объект-ның куәте | Гомум-россия үлчәү берәм-лекләре клас-сифи-кациясе буенча куәтне үлчәү берәм-леге | Ин-вести-ция юнәле-ше | Заказчы исеме | Төзүче исеме | Файда-ланугa тапшы-ру срогы | Объектның смета кыйммәте, мең сум (өстәлгән кыйммәткә салым белән) | | | | | | | | | Капитал салулар күләме, мең сум (өстәлгән кыйммәткә салым белән) | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | барлыгы | шул исәптән өстәлгән кыйммәткә салым | шул исәптән проект документациясен әзерләүгә, инженерлык тикшеренүләрен уздыруга бүлеп бирелә торган акча күләме | 2023 елга | 2024 елга | 2025 елга | 2026 елга | 2027 елга | 2038 – 2042 елларга | барлыгы | 2023 елга | 2024 елга | 2025 елга | 2026 елга | 2027 елга | 2038 – 2042 елларга |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 |
| 1. | Дэн Сяопин исемендәге Логистика комплексы 1 нче чират* | 210 663,9 | кв. метр | Төзелеш | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте | 2042 | 131 583 336,92 | 21 930 556,15 | 1 168 684,86 | 5 721 398,15 | 7 495 200,0 | 15 386 400,0 | 16 674 000,0 | 3 780 201,85 | 82 526 136,92 | 134 707 200,0 | 5 721 398,15 | 7 495 200,0 | 15 386 400,0 | 16 674 000,0 | 3 780 201,85 | 85 650 000,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2. | «Этилен-600» индустриаль паркы инфраструктурасы, Тимер юл инфраструктурасы | 1 457,57 | метр | Төзелеш | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте | 2027 | 8 799 372,1 | 1 466 562,02 | 225 931,69 | 2 282 214,44 | 2 186 734,66 | 1 765 015,37 | 1 229 613,75 | 1 335 793,88 | - | 33 878 400,0 | 5 270 400,0 | 5 050 800,0 | 4 076 400,0 | 2 840 400,0 | 3 085 200,0 | 13 555 200,0 |

*Дэн Сяопин исемендәге Логистика комплексы 1 чират шул исәптән түбәндәге этапларны үз эченә ала:
«Бер пояс, бер юл» контейнер мәйданчыгы (1 этап), смета кыйммәте – 1 758 412,43 мең сум (өстәлгән кыйммәткә салым белән);
Кәҗә краны (4 этап). «Бер пояс, бер юл» контейнер мәйданчыгы, смета кыйммәте – 531 789,84 мең сум (өстәлгән кыйммәткә салым белән).

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 7 декабрь, 1571 нче
карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 27 декабрь, 1219 нчы
карары редакциясендә)

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыру өчен 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия акчасы бүленеше

| Т/с | Капиталь төзелеш объектының исеме | Субсидияләр суммасы, сум (өстәлгән кыйммәткә салымнан башка) |
|---|---|---|
| 1. | «Этилен-600» индустриаль паркы инфраструктурасы, Дэн Сяопин исемендәге Логистика комплексы 1 чират | 52 040 400,0 |
| 2. | «Этилен-600» индустриаль паркы инфраструктурасы, Тимер юл инфраструктурасы | 1 037 959 600,0 |
| | Барлыгы | 1 090 000 000,0 |

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 7 декабрь, 1571 нче
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 27 декабрь, 1219 нчы
карары редакциясендә)

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыру өчен 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия акчасы бүленеше

| Т/с | Капиталь төзелеш объектының исеме | Субсидияләр суммасы, сум (өстәлгән кыйммәткә салымнан башка) |
|---|---|---|
| 1. | Дэн Сяопин исемендәге Логистика комплексы 1 нче чират* | 1 660 000 000,0 |
| | Барлыгы | 1 660 000 000,0 |

*«Бер пояс, бер юл» контейнер мәйданчыгы (1 этап), субсидияләр суммасы – 1 258 424 211,81 мең сум (өстәлгән кыйммәткә салымсыз);
Кәҗә краны (4 этап). «Бер пояс, бер юл» контейнер мәйданчыгы, субсидияләр суммасы – 401 575 788,19 мең сум (өстәлгән кыйммәткә салымсыз).